Тема:

«Фатих Әмирхан хикәяләрендә кабатланган тема»

3 дәрес

Кулланылган әсәрләр:

“Нәҗип”

“Корбан”

“Ул үксез бала шул! ” хикәяләре

Максат:

- **дидактик** - Ф.Әмирхан хикәяләрендәге кабатланган тема-кешенең үсүе, үзгәрүе темасының төрле яктан ачылуын аңларга ярдәм итү;
- **үстерелешле** -гомумиләштерү, охшаш күренешләр арасындагы бәйләнешне табу алымнарын формалаштыру;
- **тәрбияви**-төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү күнекмәләрен камилләштерү.

Дәрес тибы:

Уку мәсьәләсен чишү

Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.

1. Белемнәрне тигезләү:

а) Үткән дәреснең УМ нинди иде?

б) Ярым иҗади һәм иҗади өй эшләрен тыңлау.

2. УМ кую ситуациясе.

а)“Нәҗип”, “Корбан”, “Ул үксез бала шул! ” хикәяләреннән кечкенә-кечкенә өзекләр уку,

б)һәрберсенең сюжет һәм темасын кабат искә төшерү.

в)әсәрләр арасындагы охшашлык, бәйләнешне ачыклау.

II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү этабы.

1нче бирем (“Нәҗип”)

Хикәяләрнең:

- ✔ сюжетын искә төшерү,
- ✔ темасын билгеләгеләү,
- ✔ метафораларны табу.

Көтелгән җавап:

Әсәр	Метафора	Тема
“Нәҗип”	Уен: 1)урыннан кузгалмаган тарантас 2)йөзеп киткән көймә	Нәҗипнең үзгәрүе: мактанчык, ялган бер дөньяда яшәргә теләгән Нәҗип үзен җиңә.

2нче бирем (“Ул үксез бала шул!”)

Көтелгән җавап:

Әсәр	Метафора	Тема
“Ул үксез бала шул!”	Читек: 1)читек биек итеп күрсәтә 2)читек аркасында йөгерүдә артта кала	Нуриның иптәшләренең үзгәрүе: малайлар читек, бәйрәм күлмәкләре киеп, ятим Нурины мыскыллыйлар, ләкин хаталарын аңлыйлар, үкенәләр.

3 нче бирем (“Корбан”)

Көтелгән җавап:

Әсәр	Метафора	Тема
“Корбан”	Корбан: 1)бәйрәм 2)корбан чалу, ягъни бәрәнне сую.	Малайның үзгәрмәве: ул үзенә бер дөнья уйлап таба һәм шул дөньяның корбаны була, чынбарлыкны аңларга теләми.

4 нче бирем. 3 хикәяне таблицага карап гомумиләштерегез. Алар арасында охшашлыклар бармы?

Көтелгән җавап:

- һәрберсендә метафора бар,
- темалары охшаш – малайларның эчке кичерешләре.

III.Рефлексия.

- Дәреснең УМ нинди иде?

Көтелгән җавап:

- “Нәҗип”, “Ул үксез бала шул!”, “Корбан” хикәяләре арасындагы охшашлык, бәйләнеш бармы- юкмы икәнлеген ачыкларга иде.

- Аны ничек чиштек?

Көтелгән җавап:

- Хикәяләрнең сюжетын искә төшердек, метафораларны таптык, темаларны билгеләдек, җавапларны таблицаларга тутырып, нәтиҗә ясадык.

гомумиләштереп билгеләү

а) терәк конспекттан, (тактадан, эш дәфтәрләреннән) файдаланып сөйләп бирә алса - «3»;

б) терәк конспекттан файдаланмыйча сөйли алса - «4»;

в) терәк конспекттан файдаланмыйча, сүзсез (в уме) үз-үзенә сөйли алса - «5».

Өйгә эш

1. Ф.Әмирханның “Хәят” повестенең 1-7 бүлекләрен укырга, эчтәлеген сөйләргә(мәҗбүри).

2. Укылган өлештән төп каршылыкны табарга. Ул нидә? (Хәятнең күңелендә туган мәхәббәт хисе һәм аның бер хискә каршы көрәше турында язалар - яртылаш ижади эш).

3. Хәятнең портретын рәсемгә төшереп карарга (ижади эш).

- ***Танып-белү эшчәнлегенең методы:***
  - аңлатмалы-күрсәтмәле;
  - репродуктив;
  - өлешчә эзләнүле;
  - проблемалы ситуация тудыру;
  - өлешчә тикшерүле.

- ***Формасы*** – төркемнәрдә;

- ***Танып белү эшчәнлеге сыйфатын контрольдә тоту һәм бәяләү төре*** – үзконтроль, үзбәя ;

- ***Кулланылган чара*** – *дәреслек, такта, сүзлек, дәфтәр.*

- .

Башкардылар:

1. Казнина Ясима Гайнетдиновна
(МБОУ «Ново-Ашапская ООШ»,
Барда муниципаль районы, Пермь крае)

2. Кильдебаева Самига Самиковна
(МБОУ «Акбашевская ООШ»,
Барда муниципаль районы, Пермь крае)